| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**03 июнь 2024ел.** Түбән Урысбага **№ 165**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының « Түбән Урысбага авыл җирлеге советы » муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлеге советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә җирле салымнар суммасы өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә.

2. Түбән Урысбага авыл җирлеге Советының 2023 елның 1 июнендәге 125 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Х.Х.Сибгатуллин.

1 нче кушымта
Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы карарына
03.06.2024г. №165

## Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре

1 Түбәндәге нигезләр буенча түләтү мөмкин булмаган аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнелә торган 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммалары өлешендә җирле салымнар күләме буенча бурыч түләтүгә ышанычсыз дип танылa:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итмәгән очракта үлгән яисә вафат булган физик затларның бурычлары булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар өчен җирле салымнар 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган бурыч булу;

3физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар түбәндәгеләр:

1) 1 пунктның 1 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда.

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлүгә бәйле рәвештә салым органнарында исәпкә алынганнан соң физик затны төшерү турында белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе;

2) 1 пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) оешма, шәхси эшкуар, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик зат исәбе буенча салым органы белешмәсе, бурыч суммасы турында;

б) салым бетерелгән норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

3) 1 пунктның 3 бүлегендә күрсәтелгән нигез булганда, - салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч барлыгы турындагы белешмәсе.